Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 12**

Күкиавылы 2016 елның 13 июле

Авыл җирлегенең аерым мәсьәләләрен хәл
итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Күкиавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары арасында җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча аерым вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 елның 3 апрелендәге XLVIII-4 номерлы карарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башкарма комитетына түбәндәге мәсьәләне хәл итү вәкаләтен тапшыруны карарга тәкъдим итәргә:
- җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлеге башкарма комитетына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә.

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күкиавыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Күки авылы, Яңа урамы, 5 нче йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов